***РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН***
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, с.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

«15» октября 2025 ел № 361

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
КАРАР

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында 2026-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа турында

Хокук бозуларны профилактикалауның күп дәрәҗәле системасын булдыру, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген ныгыту, күрсәтелгән эшчәнлеккә җирле үзидарә органнарын, иҗтимагый формированиеләрне һәм халыкны җәлеп итү, җинаятьләр кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны локальләштерү, шулай ук "Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында" 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында һәм Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. 2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны (1 нче кушымта) расларга.

2. МКУ «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» га тиешле елларга бюджет проектын төзегәндә 2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны җирле бюджет акчалары исәбеннән финансланырга тиешле программалар исемлегенә кертүне тәкъдим итәргә.

3. 2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны гамәлгә ашыру барышында аерым чаралар төгәлләштерелергә мөмкин, ә чараларны финанслау күләмнәре, җирле бюджетның расланган чыгымнарын исәпкә алып, төзәтелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы С.Н. Балакирев